**Республика Татарстан**
**СОВЕТ**
**ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Школьная, д. 1,
с. Ляки, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ЛӘКЕ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, 1 йорт,
Ләкә авылы, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«02» нче ноябрь 2020 ел № 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы, Сарман муниципаль районы " Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар чыгарды:

Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2020 елның 12нче ноябренә 13.00 сәгатькә гражданнар җыены билгеләргә.

1. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2021 елда Ләке авыл җирлеге Дружба авыл территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидларыннан, ялгыз карт гражданнардан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән дә килешәсезме?:

- Дружба авылында янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру;

- Ләке авыл җирлегенең Дружба бистәсендә өлкәннәр һәм инвалидлар көне үткәрү өчен бүләк пакетлары сатып алу;

«РИЗА» «КАРШЫ»

2.Ләке авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында билгеләнгән срокта урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек башлыгы ______________ Л. И. Шәрипова